

ЛЕВ НИКОЛАЕВИЧ ТОЛСТОЙ

# ЛЕВ НИКОЛАЕВИЧ ТОЛСТОЙ

## 1

1841-нче ел. Россиянең ерак, караңгы провинциясендә урнашкан, урамнарына таш-фәләш түшәлмәгән, тездән баткак, тротуарлары да агачтан гына эшләнгән Казан шәһәре. Шәһәрнең иң уртасында — сасы аңкытып торган, пычрак Кузнечный мәйданы, ә арырак — бака ефәкле Черек күл һәм Мунча күле. Еш-еш янгыннар булып тора, бөтен-бөтен кварталлар яна. Күп санлы чиркәүләр — Никола Вишняков, Низкий, Ляпунов һәм Гостиный чиркәүләре — бер яналар, бер яңадан төзеләләр. «Шәһәрнең аталары» купец токымнары Крупениковлар, Унжениннар, Серебряниковлар, Петрухиннар сукно һәм сабын эшлиләр, балавыз шәм ясыйлар; алар, шәһәрне турсык йортлар һәм ак таш лапаслар белән бизәп, дәртләнеп, гостиный рәттә сату итәләр. Дворяннар Казаны шәһәрнең югары өлешенә матур йортлар сала, йорт каршысына матур бакча утырта, беседкалар урнаштыра, коймалар әйләндереп, капка башларына арысланнар ясап куя.

Икенче төрле Казан да була; ансы сазлык окраиналарга урнашкан; йортлар урнына землянкалар, алачыклар төзелгән; биредә шәһәр ярлылары, ремесленниклар яши. Мондый күп санлы бистәләрдә, сыкраучга ошап, сагышлы рус һәм татар ерлары яңгырый.

Волгага таба сузылган бистәләр аръягыннан борынгы Москва тракты уза. 1841 елның көзендә, менә шул тракт буйлап, чокыр-чакыр һәм казылмаларга төшә-төшә, Казанга таба зур бер алпавыт повозкасы килә иде. Повозкада өч малай — Сережа, Митенька һәм Лёвә Толстойлар утырган; алар, гувернерлар һәм хезмәтчеләр

ияртеп, әллә нихәтле йорт кирәк-ярагы төяп, бирегә, Азия чигендәге шушы ярым татар шәһәренә киләләр иде.

Менә юлның буеннан-буена сузылган юан ботаклы өянкеләр тезмәсе бер борылышта кинәт өзелеп калды.

— Менә Казанга да җиттек.

Лёва да түзмәде, абыйлары артыннан төште дә, оешкан аякларын язып, Казанны карарга йөгерде.

Зур шәһәр калку урыннарга матур гына булып урнашкан. Зәңгәрсу төтен эченнән чал стеналар, кремль башнясе, борынгы чиркәү күренеп тора. Бер читтәрәк, болын буенда, гаҗәеп пирамида формасында Иван Грозный памятнигы тора. Юлчылар шәһәр тирәсендәге алачыклар, сәүдә лапасләры, кибетләр янына да килеп җиттеләр.

Ясная Поляна имениесеннән алып Тула аркылы Казангача сузылган сәфәрнең ахыры якынлашты. Классик гимназиянең матур бинасы, аңардан ындарак төрмә күренде. Экипаж — Толстойларның апасы П. И. Юшкова тора торган йорт янына килеп туктады [1]. Юлчыларның каршысына хезмәтчеләр йөгерешеп чыктылар, агач колонналы биек крыльцо буйлап Пелагея Ильинична үзе дә төште.

Яшь Толстойлар тормышының Казан сәхифәсе менә шулай башланды. Арада иң кече булган Лёвочкага тик шул көннәрдә генә унөч яшь тулган иде әле.

Булачак бөек рус язучысының Казанга бу килүе очраклы гына түгел иде. Толстойлар семьясе күптән инде Казан белән нык бәйләнештә иде. Лев Николаевичның бабасының бабасы — Андрей Иванович Толстой 1754—1759 елларда биредә секунд-майор булып хезмәт иткән, ә бераз соңрак Зөядә шәһәр башлыгы булып торган; Лев Николаевичның үз бабасы — Илья Андреевичның да яшьлеге Казанда узган, һәм ул соңыннан 1815—1820 елларда Казан губернаторы булып торган иде [2]. Язучының әтисе — Николай Ильич тә егет чагында биредә озак-

---

[1] И. К. Горталов йортында тора иде. Бу йорт хәзер инде шактый үзгәргән, шулай да исән әле (Красин урамы, №17).

[2] И. А. Толстойның губернатор булып торуының соңы күңелсез бетә. «Акылга такыррак, ә характеры йомшак» булган бу кеше Казан администрациясен тәмам йөгәнсезләндерә, шуның аркасында һәр төрле тәртипсезлекләр, хаталар китә. Сенаторский ревизиядән соң Толстой эшеннән алына һәм озакламый үлә. Ул Кизичье монастыречә күмелә.

озак торган; Николай Ильичнең сеңлесе — Пелагея Ильинична Казан алпавытына — гусарский полковник В. И. Юшковка иргә чыккан; Ясная Поляна имениесеннән бик еракта торган Казанга Толстойлар менә шулай якынайганнар иде.

1830 елны Толстойларның әнисе — Мария Николаевна үлә, аңардан бераз гына соң, 1837 елда, Николай Ильич тә дөньяны калдыра. Балалар — Николай, Сергей, Дмитрий, Лев һәм Мария — апалары тәрбиясендә торып калалар: башта Татьяна Александровна Ергольскаяда торалар, аннары Александра Ильинична Остен-Сакенда һәм соңыннан Пелагея Ильинична Юшкова тәрбиясендә торалар. Толстойлар семьясенең материаль яктан кыен хәлдә калуы, шулай ук балаларга белем бирү мәсьәләсе, әлеге апаларның карары буенча, аларны Казанга китерә, Казанда исә Юшковлар үз кеше була. Казан дворяннәре каршында ул йорт бик игтибарлы санала, ә Пелагея Ильинична үзе «гәрчә бик үк гакыллы булмаса да, артык яхшы күңелле хатын булып, ультра-аристократик принциплы һәм аша чыккан свет кешесе» булып санала[1]. Лёва Толстой берничә ел гомерен менә шул П. И. Юшкова йортында уздыра. Хисләргә бай һәм тирән тойгылы эчке тормышының ул елларын Толстой безгә үзенең автопортретын «Детство, отрочество и юность» дигән әсәрендә тасвирлап күрсәтә.

Лёва төскә матур булмый. Еш кына вакыт ул, көзгегә карап, үзенең артык киң борынлы, калын иренле һәм артык кысык күзле икәнлеген күрә. Ул үзенең тупас һәм капчык шикелле фигурасы өчен дә борчыла. Болар һәммәсе аңарда самолюбияле тартыну тойгысы, бик күп төрле хисләрнең көрәшә башлавын тудыра.

Ул бик зирәк һәм яшенә караганда артык күп белә торган — үскән малай була. Игтибар белән күп кенә китаплар укып чыккан Лёва яшьтән үк үз-үзен анализлауга, философиягә бирелә башлый. Үсмер малай чагында ук инде Л. Н. Толстой симметриянең нәрсә икәнлеге турында, «кешенең положениесе белән аның мораль эшчәнлеге арасында бердәмлек булмау турында», үлем турында уйга кала торган була. Шул чакта ук инде ул

---

[1] **Н. Загоскин** — «Граф Л. Н. Толстой һәм аның студентлык еллары». «Исторический вестник» журналы. 1894 ел, январь.

«яхшы идеялларны һәм кешенең бер туктаусыз үсәргә тиешлелеген шатланып ярата» башлый.

Шул ук вакытта Лёва Толстой гадәттән тыш җитез, яхшы ук шаян, һич көтелмәгән шуклыклар ясый торган малай була. Бу вакыт ул бары тик яңа тойгы алу өчен генә берничә сажен биеклегендәге тәрәзәдән сикерә, бәхетенә каршы, ничектер, ул-бу булмый, тик җиңелчә бәрелә генә. Икенче бер вакытны тәмам хәлдән тайганга хәтле тройка артыннан йөгерүне уйлап чыгара. Ә тагын да бер көнне үзенең кашларын кырып ташлап, кешеләрне таңга калдыра.

Ул дан турында хыяллана һәм укуны артык күңелсез, гадәти эш дип таба. Ләкин шул арада инде, Толстойлар Горталов йортына килеп, үзләренең апаларында тора башлагач та, алар янына укытучылар йөри башлый. Сережа, Митенька һәм Лёвочка университетка керергә хәзерләнәләр.

Көннәр сизелми үтә башлый.

## 2

Шәһәр уртасындагы тау өстендә университет бинасы урнашкан. Тирә яктагы бер генә этажлы агач өйләр фонында ул тагын да ачыграк, килешлерәк булып күренә. Кайчандыр биредә мракобес Магницкий хуҗалык иткән була, ул бар көче белән «хөр фикерләр ачыктан ачык та, яшертен рәвештә дә дингә тел тидермәсен, аны какшатмасын» дип тырыша, философия һәм тарих фәннәрен әзәрлекләү» белән «дан» ала. Хәзер исә ул заманнар артта калган була. Хәзер учебный округ попечителе булып М. Н. Мусин-Пушкин эшли. Университет ректоры, гениаль рус галиме — геометр Николай Иванович Лобачевскийнең гүзәл эшчәнлеге менә шушы чорда җәелә. Аның җитәкчелегендә кырыгынчы ел башларында астрономия обсерваториясе, клиника, анатомия театры, китапханә һ. б. биналар эшләнеп тәмам була.

Менә шул университетка үзенең абыйлары артыннан [1], 1844 елда, уналты яшьлек Лев Толстой да укырга килә. Ул үзен көнчыгыш факультетына (дөресрәге — филосо-

[1] Николай Казан университетын 1844 елда тәмамлый, Сергей белән Дмитрий университетка 1843 елны керәләр һәм аны 1847 елны тәмамлыйлар.

фия факультетының көнчыгыш әдәбияты бүлегенә), кабул итүне сорап прошение бирә.

Л. Н. Толстой ни өчен «көнчыгыш бүлеген» сайлый соң? Чөнки утызынчы елларда, кырыгынчы ел башларында Казан университетындагы бу факультетның даны бөтен Европага таралган була. Һәм бу очраклы хәл генә дә булмый. Ул вакыттагы патша министры граф С. С. Уваровның фикеренчә, Казан университеты самодержавиенең милли окраинадагы ышанычлы таянычы булып хезмәт итәргә, «ассимиляция законының табигый агышына — көчсезрәк ыругларның көчле ыруглар тарафыннан йотылуына» булышлык итәргә тиеш була. Патша сановникларының уенча, университет бинасының каршысына беркетелгән зур алтын крестның яктысы көнчыгыш Россиянең барлык районнарына, шулай ук Төркиягә, Кытайга, Персиягә, Грузигә дә барып җитәргә тиеш була. Шул максат белән 1802 елны ук инде Казанда мөселман типографиясе төзелә, беренче гимназиядә көнчыгыш телләре укыту тәртибе кертелә, университетта да начальство тарафыннан кадерләп карала торган көнчыгыш факультеты төзелә. Атаклы лингвист М. А. Кастрен ул елларны Казан университеты турында менә нәчек яза:

«Көнчыгыш әдәбиятын Казандагы шикелле зур дәрт белән өйрәнә торган тагын берәр университет дөньяда могаен юктыр. Биредә көнчыгыш телләрен өйрәнүгә багышланган берничә кафедра: гарәп теле, әрмән, персия, санскрит, монгол, төрек, кытай, манчжур телләре кафедрасы һәм шул телләр буенча берничә саф көнчыгыш кешеләре — укытучылар бар...

Казан университеты ориенталистлары арасында Европага билгеле булганнары да бар, һәм мин ышанам: көнчыгыш мәсьәләсендә иң әһәмиятле фәнни проблемаларның чишелешен якын киләчәктә нак менә шушыннан табачаклар».

Яшь Толстойның университетта «көнчыгыш бүлеген» сайлавы университетның нак менә шундый даны аркасында булса кирәк[1].

1844 елның маенда Лев Николаевич университетка керергә экзамен тота һәм... «булдыра алмый»: гомуми

---

[1] Л. Н. Толстойның биографы — П. Н. Бирюков бу турыда әнә шундый фикерне әйтә.

рус тарихы, статистика һәм география буенча «1» билгесе ала[1]. Күп еллар үткәннән соң Лев Николаевич үзе дә тарихтан «берни дә белмәгәнлеген», ә статистика-география буенча эш «аннан да начаррак» торганлыгын әйтә.

Экзаменга учебный округ попечителе Мусин-Пушкин да катнаша; ул Юшков һәм Толстойларның танышы була: яшь Толстойга булышырга теләп, Мусин-Пушкин мондый сорау бирә:

— Я, әйтегез, Франциядә нинди диңгез буе шәһәрләре беләсез?

Лев Николаевич берне дә әйтеп күрсәтә алмый[2].

Толстойның прошениесенә: «Көнчыгыш әдәбияты бүлегенә экзам тотып карады, ләкин университетка алынырлык түгел» дип һәм: «Актларын кайтарып бирергә» дип резолюция салалар.

Толстойлар 1844 елның җәен гадәттәгечә Ясная Полянада уздыралар, ә көзен Лев Николаевич университетка кабул итүне сорап тагын прошение бирә.[3]

*„Казан Император университетының ректоры, атказанган профессор, действительный статский советник Его Превосходительство господин Николай Иванович Лобачевскийгә Лев Николаевич граф Толстойдан*

### *Прошение.*

*Үткән елның маенда мин Казан университетының гарәп-төрек әдәбияты бүлегенә керергә теләп, Казанның беренче һәм икенче гимназия укучылары белән берлектә экзамен тоткан идем, ләкин ул вакыт тарих һәм статистикадан җитәрлек күләмдә мәгълүматым барлыгын күрсәтә алмадым, шун-*

---

[1] Башка предметлардан: закон божий — 4, математика — 4, рус әдәбияты —4, логика —4, латин теле —2, француз теле —5+, немец теле—5, гарәп теле—5, төрек-татар теле—5, инглиз теле—4.

[2] **П. Н. Бирюков** тарафыннан төзелгән биография кульъязмасына Л. Н. Толстой ясаган искәрмә.

[3] Бу документ, Л. Толстойның университетта укыган вактына бәйле күп кенә башка документлар шикелле үк, төп нөсхәдән күчермә рәвешендә ТАССР ның Үзәк архивында саклана, ә төп нөсхәләр Толстой музеена тапшырылганнар.

*лыктан Ваше Превосходительстводан миңа шул предметлар буенча яңадан экзаменга керергә рөхсәт итүегезне үтенәм. Шушының белән берлектә түбәндәге документларны тапшырам: 1) Тула консисториясеннән алынган метрика таныклыгы, 2) Тула дворян депутатлары собраниесе карарыннан күчермә.*

*1844 ел августның 3 көне. Югарыда әйтелгән граф Лев Николаевич шушы прошениегә кулымны куям*".

Прошениегә мондый сүзләр язылган:

„*Өстәмә сынауга керергә рөхсәт итәм, 4 август 1844 ел. Ректор Лобачевский*".

3

Лев Николаевич Толстой инде студент булып, шпага да тага, формалап тегелгән мундир кия. Университет занятиеләренә йөри, лекцияләр тыңлый һәм Казан дворяннәренең свет тормышына һаман ныграк керә. Бу тормыш исә шау-шуга, күп санлы күңел ачу мәҗлесләренә күмелгән була. Университетта инглиз теле укытучы Турнерелли ул елларны Казандагы югары җәмгыят кешеләренең тормышлары турында болай яза:

«Мәҗлесләрне һәм бәйрәмчә яшәүне бәхет дип хис иткән кешеләр өчен, балларда йөрүне, визит бирү, визит кабул итүне генә ярата торган кешеләр өчен, ниһаять чиксез хозурлыклар эзләүче кешеләр өчен Казан — чынчын Эльдорадо иде; мин һич икеләнми әйтә алам ки, — бу кадәр еш күңел ачу мәҗлесләре ясый торган, мәҗлес һәм күңел ачулар буенча бу кадәр ярыша торган башка берәр шәһәр дөньяда юк. Күңел ачу — Казанның югары җәмгыят кешеләре өчен көндәлек ихтияҗга әйләнгән... Казанлылар танцы белән шул кадәр мавыгалар, — еш кына алар ундүртәр сәгәт рәттән бииләр.

... Казанлылар бик кунакчыл халык: һәрбер дворяндә дип әйтерлек өзлексез аш табыны була... Ким дигәндә 20—30 лап шундый йорт бар, аларга обедка көн саен һичбер чакырусыз бик күп халык җыйнала; кайда күбрәк хозурлык табарым дип өметләнсәң, шул йортны сыйлыйсың. Кофе эчеп, бераз гына бергәләп сөйләшеп алганнан соң, бары да өйләренә йокларга таралалар; бу аларда

гомуми бер гадәт булып китkән, хәтта төн буе йокламый үткәргән булсалар да, обедка җыелмый калмыйлар. Менә кич була, бар да киенә-ясана башлыйлар, аннан соң кая да булса берәр балга китәләр, балның ахрында һәркайчан бик шәп аш була... Балларның иң зур күпчелеге төн уртасынача сузыла; еш кына өйгә иртәнге биштә, алтыда кайтырга туры килә. Билгеле инде, икенче көнне төш җиткәнче йоклыйлар, ә кичен тагын шул көндәге хәл башлана.

...Казанлыларның тагын бер хозурлык тапкан эшләре — ул да карта уйнау. Монсы да аларның көндәлек ихтыяҗына әйләнеп киткән дип әйтергә мөмкин һәм ул вакыт уздырырга, акча янчыкларын җиңләйтергә ярдәм итә. Карта уенына шәһәрдәге барлык сословиеләрнең никадәр бирелгәнлекләрен хәтта аңлату да кыен. Һәммәсе: бае да, ярлысы да, эре халык та, вак халык та, картлар да, яшьләр дә, ирләр дә, хатыннар да, хәтта балалар да бар да уйный; господалар карта белән мавыгып гостиныйда утырганда, лакейләр еш кына вакыт алгы бүлмәдә уйныйлар. Җәмгыять эчендә кайный торган яшьләрнең бу уенга шул кадәр комсызлык һәм кайнар хис белән бирелүенә хәйран каласың».

Лев Николаевич Толстой борынгы дворян семьясеннән чыккан егет, өстәвенә ул Казандагы аристократик җәмгыять кешеләренең һәммәсе тарафыннан хөрмәт ителә торган Пелагея Ильинична Юшкованың энесе дә, шуңа күрә аны һәрбер дворян йорты шатланып каршылый. Балларга йөрү, «кызлар белән чана шуулар», маскарадлар, һәвәскәрләр тарафыннан куела торган спектакльләр, җанлы картиналар бер-бер артлы чиратланалар. Мондый күңел ачуларда уңышка ирешү Лев Николаевичның минминлек хисләрен кузгата. Тәскә-биткә ямьсез, буе-сыны да ничектер капчык шикелле шыксыз булган яшь егет, аруга сәбу дәрәҗәсенә җитеп, купшылана башлый, битенең нәфис булуын, озын үстерелгән тырнакларының һәрвакыт чиста булуын кайгырта, французча оста сөйләргә, шул вакыттагы сүз белән әйтсәк — comme il faut булырга, зур свет халкы арасында күркәм күренергә тырыша.

Толстойның мондый омтылышларын аның апасы хуплап тора. Лев Николаевич бу турыда соңыннан менә ничек яза: «Яхшы күңелле бу апам миңа һәрвакыт тукый иде: ирле хатын белән бәйләнештә бул, минем сиңа шуннан

да яхшы теләгем юк. Яшь егеткә иң яхшы тәэсир иткән нәрсә — ул да яхшы кругтагы ирле хатын белән бәйләнеш тоту. Апам миңа тагын бер бәхет — минем адъютант булуымны, *анда да иң яхшысы — патша адъютанты* булуымны, минем бик бай кызга өйләнүемне, мөмкин кадәр күбрәк кол биләвемне тели иде».

Көннәр менә шулай файдасыз хозурлыклар белән үтәләр. Университет занятиеләре исә тырышып, урыннан купмый укуны, түземлек һәм зур чыдамлык таләп итә. Мондый тормышның нәтиҗәсе озакламый күренә дә башлый. Кышкы сынауларда Лев Николаевич түбән билгеләр ягыннан «беренчелекне» ала. Аның өлгереше — чиркәү-библия тарихыннан өчле (тырышлык ягы 2), гарәп теленнән икеле (тырышлык ягы 3) булып чыга, бары француз теленнән генә ул бишле ала. Шук ук ведомостьтә «Гомуми әдәбият тарихы» графасы турысына — «сынауга килмәде» дип язылган.

Ләкин шундый күңелсез нәтиҗәләр дә яшь Толстойны акылга утыртмыйлар. Тиздән үзенең абыйсы Сергей белән берлектә ул хәйрия максаты белән куелган ике спектакльгә катнаша, һәм, күргән кешеләрнең әйтүенә караганда, үз ролен бик уңышлы башкара. Яшь Толстой элеккечә «һәрбер балга, кичәләргә, югары җәмгыят кешеләре җыелган җирләргә йөри, һәр җирдә кабул ителә, һәрвакыт танцовать итә, ләкин ул үзенең яшьтәшләре — «аристократ студентлар» шикелле свет дамалары өчен үлеп китми; аңарда һәрвакыт ниндидер сәер тупаслык, кыюсызлык сизелә; ул мондый урында башкарылырга тиеш булган үз роленнән кыенсына булса кирәк»[1].

Яшь Толстойның Казан университетында беренче ел укуы күңелсез бетә: ул икенче курска күчә алмый. Лев Николаевич үзе бу хәлне үзенчәрәк аңлата: «Беренче елны мине беренчедән икенче курска рус тарихы профессоры Иванов күчермәде; экзамен алдыннан гына ул минем өй кардәшләрем белән бозылышкан иде, юкса мин бер лекцияне дә калдырмаган идем һәм рус тарихын белә идем; аннан соң шул ук профессор миңа немец теленнән берле куйды; немец телен дә мин үзебезнең курстагы барлык студентларга караганда яхшырак белә идем»[2].

---

[1] **Л. Н. Толстой** әсәрләре, т., IV, бит 14, унынчы басма, М.

[2] **Н. П. Загоскин** — «Граф Л. Н. Толстой һәм аның студентлык еллары». «Исторический вестник» журналы. 1894 ел. Январь.

Дөреслеккә барсак, Лев Николаевичның бу сылтаулары икесе дә нигезсез дип әйтергә туры килә. Язучының биографлары да, архив материалларына таянып, шушы ук нәтиҗәгә киләләр. 1939 елны тагын да яңа документлар табыла[1], болар да Л. Н. Толстойның шикләнүен юкка чыгаралар.

«Көнчыгыш бүлегендә» уңышсызлыкка очрагач, яшь Толстой юридик факультетка күчерүне сорарга карар бирә.

4

Тагын көз. Шәһәрне куе яңгыр челтәре каплап алган. Фонарьләр томан эченә чак сизелерлек яктылык сибәләр. Кайсыдыр тыкырык түреннән «Слу-ш-а-ай!» дигән сузылкы аваз ишетелә. Дворяннар собраниесе бинасы бик нык яктыртылган. Анда бүген бал, аннан дәртле мазурка авазлары ишетелә. Казанның югары җәмгыят кешеләре шатланышып үзләренең кунагын — герцог Максимилиан Лейхтенбергскийны каршылыйлар.

Юридик факультет студенты Лев Толстойның уйлары университет занятиеләреннән әлекке шикелле үк ерак йөри. Ул киң кул свет тормышы эчендә яшәүдә дәвам итә, балларга чаба, аристократ-студентлар тарафыннан оештырыла торган типтерүләргә катнаша, төрле спектакльләрдә уйный. Родионовның «Институт благородных девиц» исемле уку йортында тәрбияләнүче ярлы укучылар файдасына университетның актовый залында куелган спектакльләр турында ул вакыттагы газета хәбәрчесе менә ничек яза: «Оркестр: «Ну, Карлуша, не робей!» көен уйный. Карт балыкчы үзенең җәтмәсенә бер яшь егет эләктергән һәм аны үзенең кызына тәкдим итә. Бер катлы дәү егет (граф Л. Н. Толстой) кулларын аркасына куеп, инсафлы гына басып тора: ул кылана... Карт аның иягеннән тота да, бер катлырак хәйләкәр елмаеп, кызына карый, ә кыз, аптырап, күзләрен тондырып тора... Картина гадәттән тыш уңышлы чыкты. Аны ике-өч тапкыр яңадан кабатлаттылар, бик озаклап кул чаптылар. Арада иң яхшы уйнаучы А. А. де Планьи булды (француз теле укытучысы); шулай ук кияү дә (граф Л. Н. Толстой) бик тә бер катлы чыкты»[2].

---

[1] **Г. Бушканец** тарафыннан.

[2] «Казанские губернские ведомости» газетасы, № 18, 1846 ел.

Лэкин шулай да, 1845—46 уку елында, Лев Николаевич университетка шактый күп вакыт һәм игтибар бирә. Лекцияләр белән кызыксына башлый. Күп вакытлар үзганнан соң, П. Н. Бирюковның [1] кулъязмаларын тикшергәндә, Лев Николаевич түбәндәге сүзләрне өсти: «Шушы елның ахрында мин беренче тапкыр тырышып укый башладым һәм бу эштән беркадәр тәм дә таптым. Факультетта укытыла торган предметлардан тыш мине хокук энциклопедиясе һәм җинаят эшләре правосы кызыксындырды (профессор — немец Фогель лекцияләрдә беседалар үткәрә иде, һәм мин үлем җазасы мәсьәләсе белән бик нык кызыксынганлыгымны хәтерлим); гражданское право профессоры Мейер миңа факультет предметыннан тыш эш биреп, Монтескьенең «Дух законов» белән Екатеринаның «Наказларын» чагыштырырга кушты, бу эш белән дә бик кызыксындым».

Лев Николаевич күп укый, укыган нәрсәләре турында фикер йөртә, башына килгән уйларны язып куя, төрле искәрмәләр ясый. Аның бу чордагы көнлек дәфтәрләрен карасаң, шундый тәэсир кала, — «элек йоклап яткан, ә хәзер кинәт кенә уянган гакыл, әйтерсең, барлык өлкәләрдә ныклы эшкә керешә» [2].

Тик тарих буенча гына Лев Николаевичның эше рәтләнми. Тарих лекцияләренә йөрмәгән өчен ул тиздән университет карцерына ябыла. Бу — тимер рәшәткәле, түгәрәкләнеп килгән кара түшәмле, шыксыз бер бүлмә була. Толстой белән карцерда бергә яткан В. Н. Назарьев соңрак бу турыда менә нәрсә ди: «Мин Лермонтовның «Демонын» укып утыра идем; Толстой моны күреп, шигырьгә карата гомумән ironияле караш белдерде, ә аннары, минем янда яткан Карамзин тарихына борылып, тарихны сүгә башлады, тарихны иң күңелсез, хәтта файда бирми торган предмет дип атау чигенә җитә язды.

— ... Тарих — әллә нихәтле кирәксез цифрлардан, исемнәрдән торган мәсәлләр һәм файдасыз вак-төяк нәрсәләр җыентыгы гына ул, — диде Толстой нык кистереп. — Игорьнең үлеме, Олегны чаккан елан — әкият булмыйча нәрсә соң алар? Аннары — Ионның икенче тапкыр 1562 ел 21 августта Темрюк кызына өйләнүе,

---

[1] **П. Н. Бирюков** — Л. Толстойның биографы.
[2] **П. Н. Бирюков.** «Л. Толстойның биографиясе», т. I, бит 61.

дүртенче тапкыр 1572 елны Анна Алексеевна Колтовскаяга өйләнүенең кемгә кирәге бар? Ә бит миннән менә шуларның барсын башыма төеп тутыруны таләп итәләр, белмәсәм, берле куялар. Ә тарих үзе ничек языла соң? Һәммә нәрсә тарихчы уйлап чыгарган билгеле бер үлчәүгә туры китерелә. Профессор Иванов хәзер безгә Грозный патша турында лекцияләр сөйли; менә шул патша 1560 елдан башлап мәрхәмәтлелек, мудрыйлык сыйфатларын кинәт кенә югалта да магнәсез һәм кан эчкеч тиранга әйләнә. Ничек һәм ни өчен? — бу турыда сорамагыз... — Утырдашымның фикерләре менә шушы формадарак барды. Аның фикерләренең бу кадәр кискенлеге мине уйга калдырды, ә бит мин тарихны үземнең яраткан предметым дип саный идем... Аннары Толстойның миндә зур шик тудырган көче университетка, гомумән университеттагы фәннәргә юнәлтелде. «Фән сарае» дигән сүз аның теленнән китмәде. Ул, үзе җидди кыяфәттә калганы хәлдә, безнең профессорларның портретларын шундый көлке итеп сурәтләде, — мин, никадәр генә салкын караш сакларга тырышсам да, шашкандай кычкырып көләргә мәҗбүр булдым.

— ...Хәлбуки, — диде ахырда Толстой, — бу сарайдан без барыбыз да файдалы, белемле кешеләр булып чыгарга өметләнәбез. Ә соң чынлыкта аннан нәрсә алып чыгачакбыз? Уйлагыз да туры гына җавап бирегез. Без бу гыйлем йортыннан авылга нәрсә алып кайтачакбыз? Кулыбыздан нинди эш киләчәк, кемгә кирәк булачакбыз, — ник әйтмисез?!

... Төнне менә шундый сүзләр белән үткәрдек. Таң атар-атмаста ишек ачылды, — вахмистр керде, исәнләште дә: «Сез азат, кайтырга мөмкин» дип аңлатты. Толстой фуражкасын батырып киде, шинелен төренде, миңа җиңелчә генә баш кагып, әлеге «сарайны» тагын сүгеп алды да үзенең лакее һәм вахмистр белән бергә чыгып китте. Мин дә тизрәк чыгарга ашыктым, утырдашымнан котылып, әле яңа гына уяна башлаган тын урамның салкын һавасын иркенләп суладым.

... Башым әлеге сәер, һәм аңлап булмый торган иптәшемнең минем өчен бөтенләй ят тоелган шикләнүләре, сораулары белән тулган, ис тигәндәге шикелле авырайган иде» [1].

---

[1] В. Н. Назарьев. «Жизнь и люди былого времени». «Исторический вестник» журналы. Ноябрь, 1890 ел.

1846 елның маенда Лев Николаевич икенче курска күчерелә. Өлгереше: логика һәм психология — 5, хокук энциклопедиясе, Рим хокукы тарихы һәм латин теле — 4, гомуми рус тарихы, матур сөйләү теориясе һәм немец теле — 3; һәм үз-үзен тоту буенча өч бишлесе була.

Шул ук елның көзендә Толстойлар (Сергей, Дмитрий һәм Лев) П. И. Юшкова йортыннан икенче квартирага — Казан архитекторы Петонди йортына күчәләр. Алар анда ишек алдындагы таш флигельнең өске этажын билиләр[1]. Юшковлар йортыннан, өзлексез кунак кабул итеп, кичәләр оештырып яшәүче свет кешеләре йортыннан, китү — Лев Николаевичның укуына яхшы йогынты ясар, ул тырышыбрак укый башлар дип уйларга мөмкин иде. Ләкин алай булып чыкмый. Л. Н. Толстойның настроениеләре үзгәрә. 1847 елның гыйнварендә булган ярты еллык сынауларда ул инде көч-хәл белән бары берничә предметны гына бирә ала, һәм пасха каникуллары үтү белән үк, университеттан чыгаруны сорап прошение бирә.

*„Казан Император университеты ректоры, действительный статский советник һәм кавалер Его Превосходительство господин Иван Михайлович Симоновка.*

*Юридик факультетның икенче курсында укучы — үз акчасына киченеп торучы студент граф Лев Николаевич Толстойдан*

***Прошение.***

*Сәламәтлегем булмау һәм йорт мәшәкатьләре килеп чыгу сәбәпле, университетта укуны дәвам иттерә алмаганлыгымнан, Сез Ваше Превосходительстводан үтенеп сорыйм,— мине университеттан чыгару һәм документларымны кайтару турында үзегезнең әмерегезне бирсәгез икән. Шушы прошениегә кулымны куям студент граф Лев Толстой. 1847 ел апрельнең 12 көне“.*

Лев Николаевич Толстойның «университетта укуы турында» мондый таныклык бирәләр.

---

[1] Элекке Покровский һәм Поперечно-Казанский урамнар чатындагы (хәзерге К. Маркс һәм Красин урамнары чатындагы) бу йорт хәзер дә исән, тик беркадәр үзгәртелгән.

*„Моны күрсәтүче граф Лев Николаевич Толстой, башта үзенең өендә укып, гимназиянең бөтен курслары өчен экзамен тотты һәм Казан университетының гарәп-төрек әдәбияты бүлегенә беренче курска студент итеп кабул ителде, ләкин аның бу курста ничек укыганлыгы мәгълүм түгел, чөнки еллык сынауларга килмәде, шунлыктан шул ук курста калдырылды; Казан учебный округының господин управляющие тарафыннан 1845 ел 13 сентябрьдә бирелгән 3919 номерлы рөхсәт нигезендә, гарәп-төрек әдәбияты бүлегеннән юридик факультетның беренче курсына күчерелде, анда исә түбәндәгечә укыды: логика һәм психология — отлично, хокук энциклопедиясе, Рим хокукы тарихы һәм латин теле — яхшы, гомуми тарих һәм рус тарихы, матур сөйләү теориясе һәм немец теле — канәгатьләнерлек; шушы өлгереш белән икенче курска күчерелде, ләкин анда ничек укыганлыгы мәгълүм түгел, чөнки әле еллык сынаулар булмаган. Ул, Толстой, университетта уку чорында үзен отлично тотты. Быел исә, сәламәтлеге булмау һәм семья мәшәкатьләре аркасында аның үзе тарафыннан 12 апрельдә бирелгән прошение нигезендә университеттан чыгарылды, шулай итеп ул, господин Толстой, университет фәннәренең тулы курсын үтмәгәнлектән, башка тулы хокуклы студентларга бирелгән хокуклар белән файдалана алмый, ә гражданский хезмәткә кергән вакытта, 1842 елда чыккан Законнар Җыентыгының III том 590 статьясе нигезендә, чин буенча урта мәктәп тәмамлаган кешеләр белән бер тигез итеп карала һәм гражданский чиновникларның икенче разрядына кертелә. Шуларны раслап, Казан университеты правлениесе аңа, граф Лев Толстойга, тиешле имзалар куеп, һәм патша хәзрәтләренең Казан университетына биргән грамотасы нигезендә казенный печать басып, шушы таныклыкны бирде".*

Күренә ки, Толстойның университеттагы уңышсызлыклары, бигрәк тә көнчыгыш бүлегендә икенче курска күчә алмавы, бу таныклыкта бик оста итеп читләтеп үтелгән.

Сергей һәм Дмитрий Толстойлар шушы елны университетны тәмам итәчәк булалар, ләкин Лев Николаевич абыйларының укып бетерүен көтеп Казанда калырга теләми, ул Ясная Полянага китәргә ашыга. Апрель иртәләренең берсендә Толстойлар квартирына Лев Николаевичның дус студентлары җыела. Алар, уен-көлке катыштырып, шаулашып, бәхетле юл телители, дуслык бокаллары күтәрәләр. Лев Николаевичны Казанка перевозына хәтле озата баралар.

Менә инде бер борылышта Кремльнең ак стеналары һәм башнясе күздән дә югала. Экипаж борынгы Москва тракты буйлап сузылган юан ботаклы өянкеләр тезмәсе эченә керә.

5

Күп еллар узганнан соң, Лев Николаевич, университеттан китүенең сәбәпләренә тукталып, болай яза: «Университеттан китүемә ике нәрсә сәбәп булды: 1) абыем университетны тәмамлап китәчәк иде, 2) ничек кенә гаҗәп булмасын, «Наказ» һәм „Esprit des lois" өстендә эшләү (ул миндә хәзер дә бар) минем каршымда яңа өлкә, үзлегеңнән гакыл хезмәтенә бирелү өлкәсе, ачты, ә университет мондый эшкә булышлык күрсәтми, киресенчә, үзенең таләпләре белән аңа җайсызлый иде». Икенче бер вакыт, үзенең немец биографы белән беседасында, Лев Николаевич тагын шул университеттан зарлана: «Казандагы укытучыларның лекцияләре мине аз кызыксындыралар иде. Башта мин көнчыгыш телләре укыдым, ләкин бик начар өлгердем. Мин зур дәрт белән берьюлы күп эшкә бирелдем, чиксез күп санда китап укыдым, ләкин һаман бер үк юнәлеш белән бардым. Әгәр мин бер-бер мәсьәлә белән кызыксынсам, аннан уңга да, сулга да тайпылмый идем, шул бер мәсьәлә буенча дөньяда күпме маглүмат булса, барсы белән дә танышырга тырыша идем».

Казан университетына каратылган бу сылтаулар дөресме соң? Үткән йөзнең кырыгынчы елларында Казан университеты чынлап та шул дәрәҗәдә үк начар идеме? Без әйтеп киткән идек инде: Мусин — Пушкин попе-

чительлек иткән һәм Лобачевский ректор булып торган чорда университет тамырыннан ук үзгәрә. Дөрес, укытучылар арасында әле очраклы килеп эләккән һәм талантсыз кешеләр дә байтак була, ләкин шулар белән бер рәттән биредә Лобачевский, Зинин шикелле менә дигән галимнәр булганлыгын, Н. Иванов, Сименов, Аристов һ. б. ш. күренекле укытучылар булганлыгын да әйтергә кирәк. Шул чакларда ук инде университетта фәнни эш кайный. Күп кенә студентлар, Лев Николаевичның яшьтәшләре, Казан университетыннан уңышлы рәвештә яхшы ук белемнәр алып чыгалар. Биредә А. М. Бутлеров, В. Берви (Н. Флеровский) кебек кешеләрне генә әйтеп китү дә җитә. Аннары килеп Лев Николаевич үзе дә 1845 елның көзеннән башлап «беренче тапкыр нак менә шул университетта нык лап укырга керешкәнлеген», нак менә шул чорларда инде үлем җәзасы турында профессор Фогель лекциясендә үткәрелгән беседа белән «бик нык кызыксынганлыгын», шунда гыйлми эшкә тотынганлыгын әйтеп бирә. Әгәр дә Казандагы дворян җәмгыятенең котырып кайнаган свет тормышы җәйсызламаган булса, Толстойның университеттагы занятиеләре уңышлы гына дәвам итәр һәм алга китәр иде. Баллар, маскарадлар яшь Толстойны мавыктыралар, зур көч куюны таләп итә торган университет занятиеләрен бик нык чыгырыннан чыгаралар. Ул вакытта аристократ-студентлар арасында университет фәннәренә модный бер нәрсә итеп, ләкин күңелсез, хәтта кирәксез, ялыктыргыч бер эш итеп, карау тенденциясе таралган була. Лев Николаевич, әнә шул аристократик җәмгыят белән тәмам бәйләнештә булганы хәлдә, «укып йөри һәм күңел дә ача»; укый, ләкин тырышмый һәм педагоглар тарафыннан «бик ялкау» дигән бәяне ала.

Көннәр үтә, экзаменнар аның саен яңа, ләкин күңелсез нәтиҗәләр бирәләр. Университеттагы менә шул «сөртенүләр» Толстойның ауру катыш мин-минлегенә нык удар ясыйлар. Университет фәннәреннән күңел суыну килеп чыга. Шуның белән бергә яшь Толстой шул вакытта ук инде үзен үзеннән олы аристократ-студентлардан өстен итеп хис итә, «ул господаларны ахмаклар» дип исәпли.

Үзенең «Исповедь» (Тәүбә) исемле әсәрендә Л. Н. Толстой яза: «Ул елларны исәпләсәм, йөрәгем сыкрый башлый, котчыккыч җирәнү сизәм. Мин яхшы булырга бөтен көчем белән тырыша идем. Ләкин мин яшь идем,

минем үземнең дәртләрем бар, ләкин ялгыз идем. Күңелемдәге иң кыйммәтле хисләрне әйтеп бирергә теләсәм, һәрвакыт кимсетүле караш очрата идем, ә инде үткен теләкләргә бирелеп китсәм, мине шунда ук мактыйлар, хуплыйлар иде».

Толстой шул тормыштан чыгу юлын эзли һәм «зуррак, җанлырак, файдалырак эшкә керешү өчен» Ясная Полянага кайтып китә.

Толстойның Казандагы тормышы аның иҗатында эзсез калмый. Казанда ул аристократик чолганыш эченә чума, «свет» тормышын күрә, күп кенә кыйммәтле күзәтүләр, тәэсирләр ала, һәм болар аның күп кенә художество әсәрләрендә чагылалар. Гениаль Лобачевский заманындагы Казан университеты Толстойга шулай ук үзенең йогынтысын ясый. Николай Иванович Лобачевский кебек, Аристов, Мейер һ. б. ш. кебек алдынгы профессорлар — фикер ияләре ул елларда университеттагы гакыл эше һәм фәнни эш настроениеләрнең гомуми юнәлешенә күп йогынты ясыйлар, ә яшь Толстой әнә шул университет һавасын сулый.

Яшьтән үк бик катлаулы, философик мәсьәләләр турында фикер йөртергә өйрәнгән Толстой Казанда Руссоны укый, Монтескье өстендә һәм Екатеринаның «Наказы» өстендә утыра. Бу эш аны — дәүләт идарәсе республика формасында булырга тиеш дигән фикергә, власть — көчләү белән яши алмый, ул халык ихтияры белән яшәргә тиеш, халык «үзе өстеннән үзе идарә итә» дигән фикергә китерә. Философик китаплар уку аны яшьтән үк һәм аңлы рәвештә «диннән ваз кичүгә» китереп җиткерә. Лев Николаевич һичкемнең котыртуыннан тыш чиркәүгә йөрүдән, ураза тотудан туктый. Ул «свет» тормышы турында болай фикер йөртә: «Свет халкының күп өлеше үзләренең юньсез тормышларын яшьлек нәтиҗәсе дип карыйлар, чынында исә бу бер дә башка нәрсә түгел, ә күңелнең яшьтән үк бозыклыкка бирелү нәтиҗәсе генә»; шуңардан чыгып, Лев Николаевич шәхси тормышны, үзенең «Мин»ен камилләштерү мәсьәләләре буенча һаман ныграк уйлана башлый.

1847 елның 17 апрелендә, ягни Казаннан китәр алдыннан, ул үзенең көнлек дәфтәренә менә нәрсә яза: «Тормышта үзгәреш булырга тиеш, ләкин бу үзгәреш тышкы вакыйгаләр нәтиҗәсе булмасын, ә күңел үзгәреше нәтиҗәсе булсын». Тагын: «Яшәүдән максат — яшәмәктә

булган һәммә нәрсәнең бөтен яклап үсүенә аңлы рәвештә омтылу».

Шул ук дәфтәрдә без яшь Толстойның мондый фикерләрен очратабыз:

«Хатыннар җәмгыятенә җәмгыят тормышындагы зарур бер күңелсез нәрсә итеп кенә кара һәм алардан мөмкин кадәр ерак кач... Чынлап та: без соң төчеләнү, иркәләнү, бөтен нәрсәгә җиңел карау сыйфатларын һәм бик күп башка бозыклыкларны хатыннардан алмыйча кемнән алабыз? Безгә тумыштан ук бирелгән хисләрнең: кыюлык, катылык, уйлап эшләү, гаделлек һ. б. хисләрнең бездә югала баруына хатыннар гаепле булмыйча кем гаепле? Хатыннар ирләргә караганда тәэсиргә тизрәк бирелүчәннәр, шуңа күрә үткәндәге гонаһсыз гасырларда алар бездән яхшырак булганнар; хәзерге азгынлык, бозыклык гасырында алар бездән начаррак». Яшь Толстойның көнлек дәфтәрләрендәге менә шундый фикерләр, шулай ук гомренең Казанда үткән елларына бәйләнешле булган беренче философик тәҗрибәләр — хезмәтләр («Философиянең максаты», «Киләчәк тормышка карата фикер йөртү турында», «Вакытны, пространствоны һәм санны билгеләү», «Методлар» һ. б.) — болар безгә Лев Николаевичның — фикер иясе — художникның гигант эшчәнлеге Казанда башланганлыгы турында әйтәләр.

* * *

Моннан утыз ел элек, болытлы ноябрь иртәләренең берсендә, Казан газеталары траурлы игланнар белән чыгалар: «Толстой үлде!» диелә. Бөек рус язучысының яшьлек таңындагы мәктәбе булган Казан университеты умарта күчедәй туза, гүли, студентлар хисапсыз күп сходкалар уздыралар. Сходкалар университет начальствосының рәсми тыюына каршы буларак уздырыла. Казан студентлары, гениаль художникка үзләренең соңгы сәламнәрен тапшыру өчен, үзара акча җыешып Ясная Полянага делегация җибәрәләр һәм патша чиновникларының каршы торуына карамастан, Казан университетының элекке студенты Лев Николаевич Толстой университетның почетлы студенты булып китә.

Аннан соң инде күп еллар үтте. Бөек социалистик революция көннәре, данлыклы, ялкынлы көннәр килде. Казан университетының ишекләре хезмәт ияләренең ба-

лалары өчен киң ачылды. Аңа ел саен йөзләрчә яңа студентлар, социалистик ватанның дөньяда иң бәхетле булган уллары һәм кызлары, килеп торалар. Һәм алар, шушы тарихи бинага керәп аяк басу белән, дулкынланып хәтерлиләр:

— Биредә Ленин укыган...

— Биредә Толстой укыган...

Алар социалистик революциянең бөек юлбашчысы В. И. Ленин сүзләрен — рус әдәбиятында мәңге яшәр әсәрләр тудыручы Л. Н. Толстойның бөеклеге, гениальлеге турындагы сүзләрне хәтерлиләр.

*В. Дьяконов.*